Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр керту хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9) үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы Президенты указында билгеләнгән тәртиптә белешмәләр бирергә;";

2) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен чикләүләр**

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш, Россия Федерациясе

234

Хөкүмәте әгъзалары өчен билгеләнгән чикләүләр федераль законнар нигезендә кагыла.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 9 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) 2010 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 21 декабре
№ 73-ТРЗ